ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2025 г.Лениногорск № 7

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә Җирләү һәм күмү эше турында» 2025 елның 11 февралендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 28 декабрендәге 1243 номерлы карарына таянып, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы белән, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә Җирләү һәм күмү эше турында» 2025 елның 11 февралендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә Җирләү һәм күмү эше турындагы Нигезләмәдә:

беренче абзацта «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары белән», » сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2, 8.4, 9.4 пунктларда «5,0 кв.м (2,0 м х 2,5 м) тәшкил итә (2,2 м тирәнлек)» сүзләрен «2,0 м х 1,0 м х 2,2 м тәшкил итә (озынлыгы, киңлеге, тирәнлеге)» сүзләренә алмаштырырга.»;

7.3 пунктта «5,0 кв.м (2,0 м х 2,5 м) тәшкил итә (2,2 м тирәнлек)» сүзләрен «2,0 м х 2,5 м х 2,2 м тәшкил итә (озынлыгы, киңлеге, тирәнлеге)» сүзләренә алмаштырырга.».

2.Әлеге карарны рәсми публикаторда - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтына (http://leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72